ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының $11^2$ статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 18 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $11^2$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«$11^2$ статья. **Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру**

1. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга әлеге максатларда булдырыла торган махсуслаштырылган оешмаларда ярдәм күрсәтелә.
2. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмалар (алга таба – махсуслаштырылган оешмалар) дәүләт, муниципаль учреждениеләр рәвешендә төзелә.
3. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләрендә оештырылган махсуслаштырылган оешмаларда күрсәтелә: Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Азнакай муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль

районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Чистай муниципаль районы.

4. Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру вәкаләтләре, махсуслаштырылган оешмалар төзүне дә кертеп, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына башкару өчен тапшырылырга мөмкин.

5. Җирле үзидарә органнары алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерү халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын җирле бюджетлар керемнәре хисабына гамәлгә ашырырга хокуклы, моңа Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлар һәм өстәмә түләү нормативлары буенча салым керемнәре керми.

6. Махсуслаштырылган оешмаларның эшчәнлеге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган кагыйдәләр нигезендә оештырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 08 апрель
№ 22-ТРЗ